КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 октябрь 20 г.Казань № 932

Балык Бистәсе муниципаль районында «Акчарлак» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приюты» дәүләт казна учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының йорт адресы буенча урнашкан «Балык Бистәсе муниципаль районында «Акчарлак» балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приюты» дәүләт казна учреждениесен (алга таба - «Акчарлак» социаль приюты) бетерү турында тәкъдимен кабул итәргә

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

әлеге карар кабул ителгән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнгән 14 көн эчендә:

«Акчарлак» социаль приютының ликвидация комиссиясе составын расларга;

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә «Акчарлак» социаль приютын бетерү тәртибен һәм срокларын билгеләргә;

эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә теркәүче органга, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен, «Акчарлак» социаль приютының бетерү процессында булуы турында белешмәләр тапшырырга;

әлеге карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән, шул исәптән ликвидацияләнә торган

учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән күчемсез мөлкәттән, шулай ук күчемсез милек объектларына техник документацияләрдән файдалану турында тәкъдимнәр тапшырырга;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә бетерү нәтиҗәсендә азат ителгән хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә, шулай ук «Акчарлак» социаль приютын бетерү буенча законнарда каралган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. »Акчарлак» социаль приюты йөкләмәләре буенча җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органы, шул исәптән суд карарларын үтәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча да, «Акчарлак» социаль приютын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, календарь көннәрендә исәпләнгән 60 көн эчендә, законнар белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан бирелгән мөлкәт исемлеге нигезендә, элек «Акчарлак» социаль приютына беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт милкен тапшыруны тәэмин итәргә.

4. »Акчарлак» социаль приюты структурасын бетерү чаралары башкарылганнан соң бушатылган акчалар «Өлкән буын гражданнарына (Татарстан Республикасы) системалы ярдәм күрсәтү һәм тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм тормышка ашыру» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында психоневрологик интернатларда тәрбиячеләрнең штат санын арттыруга, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга хезмәт күрсәтүче стационар учреждениеләр өчен аз реабилитация чаралары һәм җиһазлар сатып алуга юнәлдерелә.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертергә һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин